**СОВЕТ ДАЧНОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район
п. Дачное, ул. Центральная, д. 34

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДАЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк ур., 34

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19 октябрь 2020** **№9 нчы**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль район Дачный авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчләрен югалткан дип таныргa:

Биектау муниципаль районының Дачное авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 маендагы 17 номерлы «Дачное авыл җирлеге территориясендә тышкы төзекләндерү, тиешенчә тоту, җыештыру, чисталыкны һәм тәртипне тәэмин итү кагыйдәләре» карары;

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 мартындагы 6 нчы номерлы «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау турында» карары;

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 мартындагы 8 нче номерлы «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау турында» карары

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 мартындагы 6/1 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына тапшыру турында» карары;

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 августындагы 183 нче номерлы «Дачный авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итү буенча Биектау муниципаль районы Советына тапшырыла торган вәкаләтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» карары;

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 мартындагы 8.1 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» карары;

Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2015 елның 26 маендагы 19 номерлы «Дачный авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм санитар тәртип кагыйдәләрен раслау турында » карары;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2015 елның 26 маендагы 21 номерлы «Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында » карары;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Жильцов